**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнәмуниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге**
**Советы**

422008, Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авылы,
Советская урамы, 33
тел. 3-60-38, факс 3-60-38

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Совет Кунгерского сельского поселения**

422740, Атнинский муниципальный район
с.Кунгер,
ул. Советская, 33
тел. 3-60-38, факс 3-60-38

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» ноябрь 2019 ел. № 9

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл жирлеге Күшәр торак пунктында гражданнарнын үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә жирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл жирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл жирлеге Күшәр авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 21 ноябрендә 19 сәгать 30 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык жыенының беренче этабын билгеләргә: Татарстан урамы, Х.Такташ урамы, Сәйдәшев урамы, Тукай урамы.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл жирлеге Күшәр авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 23 ноябрендә 19 сәгать 30 минутта үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык жыенының икенче этабын билгеләргә: Комсомольская урамы, Фрунзе урамы, Октябрь урамы.

3. Билгеләргә:
- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл жирлеге Күшәр торак пунктында үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык жыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл Башкарма комитеты;
- гражданнар жыенының беренче этабын уздыру вакыты - 21 ноябрь 2019 ел 19.30 сәг.тән 20.30 сәг.кә кадәр;
- гражданнар жыенының икенче этабын уздыру вакыты - 23 ноябрь 2019 ел 19.30 сәг.тән 20.30 сәг.кә кадәр;
- Гражданнар жыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны - Күшәр авылы, Г.Тукай урамы, 21 йорт, Күшәр авылы мәдәният йорты залы.

4.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 15ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл Башкарма комитетында гражданнар жыены карарына

чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Күңгәр авылы, Советская урамы, 33 йорт

- Сайлау хокукына ия булган Күшәр торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергэ;
- Гражданнар жыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;
- Күшәр торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.
-

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Күңгәр авыл жирлеге Күшәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга, 500 сум күләмендә үзарасалым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
   - Күшәр авылы территориясендәге Ашыт елгасы чокырыннан су агызу өчен канауны тирәнәйтү;
   - Күшәр авылы көтүлегендә, елга аша маллар чыгу өчен куперчек төзү өчен төзелеш материаллары сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Күңгәр авылы, Советская урамы., 33 йорт, Күшәр авылы, Г.Тукай урамы, 21 йортларындагы мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
7. Әлеге карар, ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Күңгәр авыл җирлеге башлыгы: Г.Х.Гарипова